ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05.11.2024 ел Баулы шәһәре № 151

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы «Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерияләре һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт хакын түләүне оештыру һәм аның шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы финанс Министрлыгының 2024 елның 7 октябрендәге 03-12/7086 номерлы Башкарма комитетларның структур бүлекчәләре булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерияләр һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт хакын түләүнең 2025 елның 1 гыйнварыннан яңа системасын кертү турында хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 104 номерлы «Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтерияләре һәм бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре җитәкчеләренә, белгечләренә хезмәт хакын түләүне оештыру һәм аның шартлары турында» (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 4 сентябрендәге 178 номерлы, 2020 елның 2 октябрендәге 191 номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 221 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 260 номерлы, 2024 елның 4 июнендәге 83 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан

Республикасы Баулы муниципаль районы «Мәгариф бүлеге үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы спорт һәм туризмны үстерү бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы яшьләр эшләре бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт хакын түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмәдә:

3 пункт таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сумнарда | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәләре (бүлекләре) булып торучы муниципаль казна учреждениеләренең үзәкләштерелгән бухгалтериясе, бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлекләре өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 33 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 31 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 31 500 |
| Бүлек начальнигы | 27 700 | 27 700 |
| Әйдәүче бухгалтер | 25 300 | 25 300 |
| Бухгалтер | 24 000 | 24 000 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров